Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 3 октябре № 9

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә " Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең Кече Әшнәк филиалын бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гражданнар җыелышын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясы, «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең Кече Әшнәк филиалын бетерү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 12 октябренә 15 сәгать 30 минутта «Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең Кече Әшнәк филиалы бинасында гражданнар җыелышын билгеләргә, адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Кече Әшнәк авылы, Кызылармия урамы, 32а йорт (алга таба-гражданнар җыелышы).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

2.1.гражданнар җыелышын әзерләү һәм үткәрү;

2.2. гражданнар җыелышын үткәрү нәтиҗәләре буенча беркетмә әзерләү;

2.3. гражданнар җыелышының нәтиҗәләрен билгеләнгән тәртиптә уздырганнан соң бер ай эчендә игълан итү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Р.А.Хөснетдинова